ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» февраля 2026 ел № 41

2026 елга Әгерҗе муниципаль районында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатларында салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган «Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы белән», «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 153 номерлы карары нигезендә, "Бәяләр диапазонын билгеләү турында" 05.02.2026 елның 23 номерлы коммерцияле булмаган партнерлыкның "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга Әгерҗе муниципаль районында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатларында әлеге карарның 2 пункты нигезендә исәпләнгән түбәндәге чик күрсәткечләрен расларга:

1.1. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга керемнең чик әһәмияте 38 597,14 сум күләмендә;

1.2. гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге, салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткече:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 026 000,00 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаиләләр – 2 052 000,00 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаиләләр – 3 078 000,00 сум;

1.2.4. дүрт кешедән торган гаиләләр –4 104 000,00 сум;

1.2.5. биш кешедән торган гаиләләр – 5 130 000,00 сум;

1.2.6. алты кешедән торган гаиләләр – 6 156 000,00 сум;

1.2.7. җиде кешедән торган гаиләләр – 7 182 000,00 сум;

1.2.8. сигез кешедән торган гаиләләр – 8 208 000,00 сум.

2. 2026 елга Әгерҗе муниципаль районындаһәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасын һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын расларга.

3. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Секторына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны, гражданнарны аз керемлеләр дип таныганда һәм аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә куйганда, торак шартларын яхшыртканда файдаланырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.01.2026 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының 27.02.2026 елның 41 номерлы
карары белән расланды

**2026 елга Әгерҗе муниципаль районында һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатларында салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау методикасы**

1. Базар бәясенең исәп күрсәткече:

**СЖ= НП*РС* РЦ**, кайда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча базар бәясенең исәп күрсәткече яисә торак урын сатып алу бәясенең бусагасы;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе, Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2026 елның 05 февралендәге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының хаты нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 2025 елга 57 000,00 сум күләмендә билгеләнгән.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: СЖ=57 000*18= 1 026 000,00сум

б) ике кешедән торган гаиләләр: СЖ= 57 000*18*2=2 052 000,00 сум

в) өч кешедән торган гаиләләр: СЖ=57 000*18*3=3 078 000,00сум

г) дүрт кешедән торган гаиләләр: СЖ=57 000*18*4=4 104 000,00 сум

д) биш кешедән торган гаиләләр: СЖ=57 000*18*5=5 130 000,00 сум

ж) алты кешедән торган гаиләләр: СЖ=57 000*18*6=6 156 000,00 сум

з) җиде кешедән торган гаиләләр: СЖ=57 000*18*7=7 182 000,00 сум

и) сигез кешедән торган гаиләләр: СЖ= 57 000*18*8=8 208 000,00сум

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече (ПД):

**ПД=0,7хСЖхПС/(1-(1+ПС)$^{-КП}$) /(0,3хРС)**, кайда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) (19/12/100=0,0158, анда 2026 елда кредитлар буенча 19 процент ставкасы)

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (20 ел яисә 240 ай кредит бирү срогы «Татарстан Республикасы ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматы нигезендә);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте;

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтен исәпләү**

Табл. № 1

| НП - торак урын нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х х х РЦ) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынының базар бәясе (сум) | ПС - Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | Керемнең чик күрсәткече (сум.) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 57 000,00 | 19/12/100= 0,0158 | 240 | 0,7 | 0,3 | 38 597,14 |
| 18 | 1 026 000 | 1 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 0,3 | 38 597,14 |
| 36 | 2 052 000 | 2 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 0,6 | 38 597,14 |
| 54 | 3 078 000 | 3 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 0,9 | 38 597,14 |
| 72 | 4 104 000 | 4 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 1,2 | 38 597,14 |
| 90 | 5 130 000 | 5 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 1,5 | 38 597,14 |
| 108 | 6 156 000 | 6 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 1,8 | 38 597,14 |
| 126 | 7 182 000 | 7 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 2,1 | 38 597,14 |
| 144 | 8 208 000 | 8 | 57 000,00 | 0,0158 | 240 | 0,7 | 2,4 | 38 597,14 |

**Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган гражданның яисә ялгыз яшәүче гражданның уртача айлык җыелма кеременең чик күләмен исәпләп чыгару**

1. Ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) $^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 1 026 000,00 х0,0158 / (1 –(1+0,0158)$^{240}$) / (0,3 х 1) = 11 347,56/1-0,023/03 = 11 347,56/0,98/0,3=38 597,14

2. Ике кешелек гаиләгә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС) $^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 2 052 000,00 х0,0158 / (1 –(1+0,0158)$^{240}$) / (0,3 х 2) = 22 695,12/1-0,023/0,6=22 695,12/0,98/0,6 = 38 597,14